**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# БОЕРЫК

«21» 03 2019 ел Яр Чаллы № 49

Тукай муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 18 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 592 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 24 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 678 санлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын раслау турында» 2013 елның 25 июнендәге 2441/13 санлы приказына үзгәрешләр кертү хакында» 6162/15 санлы приказы нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийләрен расларга (1 кушымта).
2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийләрен расларга (2 кушымта).
3. Әлеге боерыкны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 21.03.19 49 санлы боерыгына 1 кушымта

## Фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийләре

| № | Эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Үлчәнеш коэффициенты | Индикаторлар диапазоны | Вакытлылык | Исәпләү методикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Рус теленнән БДИ буенча уртача балл | берәмлек | 10 | 0 - 10 | еллык | УРК - уртача республика күрсәткече<br>УРКнән түбән - 0 балл<br>УРК белән тигез яки 2,9 берәмлеккә артыграк - 3 балл<br>УРКнән 3-4,9 берәмлеккә артыграк - 5 балл<br>УРКнән 5 берәмлеккә артыграк - 10 балл |
| 2. | Математикадан БДИ буенча уртача балл | берәмлек | 10 | 0 - 10 | еллык | |
| 3. | Сайлап алган фәннәрдән БДИ буенча уртача балл | берәмлек | 10 | 0 - 10 | еллык | |
| 4. | Рус теленнән ТДИ буенча уртача балл | берәмлек | 10 | 0 - 10 | еллык | УРКнән түбән - 0 балл<br>УРК белән тигез - 3балл<br>УРКнән 0,1- 0,4 берәмлеккә артыграк - 5 балл<br>УРКнән 0, 5 берәмлеккә артыграк - 10 балл |
| 5. | Математикадан ТДИ буенча уртача балл | берәмлек | 10 | 0 - 10 | еллык | |
| 6. | ДЙА нәтиҗәләре буенча аттестат алмаган 11 нче сыйныф укучылары булмау | очрак | 10 | 0 - 10 | еллык | Аттестат алмаган чыгарылыш укучылары булмау - 10 балл;<br>Аттестат алмаган чыгарылыш укучылары булу - 0 балл |
| 7. | Татар телен туган тел буларак өйрәнүче татар милләтеннән булган укучылар саны | % | 10 | 70-85<br><br>милли оешмалар өчен 84-95 | еллык | N=(A/B)*100%<br>биредә А - татар телен туган тел буларак өйрәнүче татар милләтеннән булган укучылар саны;<br>В – татар милләтеннән булган укучыларның гомуми саны<br><u>Рус телле мәктәпләр өчен</u>:<br>69% тан кимрәк - 0 балл<br>70-74% - 3 балл<br>75-79% - 6 балл<br>80-84% - 8 балл<br>85% - 10 балл<br><u>Татар мәктәпләре өчен:</u><br>83% тан кимрәк - 0 балл<br>84-89% - 5 балл<br>90-95% - 10 балл |